**СОВЕТ ТУКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫСОВЕТЫ**

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. :Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

19.02.2015 № 35/3

№__________от_______________

**КАРАР**

**2012 елның 20 июнендәге 13/1 номерлы муниципаль берәмлек Советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (икенче укылыш)**

Федераль законнардагы һәм Татарстан Республикасы законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 нче статьясына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында 2014 елның 23 июнендәге 165-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль район Уставының 88, 89 статьялары нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

2012 елның 20 июнендәге 13/1 номерлы Совет карары белән расланган «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлекләрне электр, җылылык, газ белән тәэмин итүне район чикләрендә тәэмин итүне оештыру;»

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) район чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, район чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын муниципаль тикшереп торуны гамәлгә ашыру һәм аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) эшчәнлеген булдыруны һәм тәэмин итүне кертеп, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;»

в) 6 пунктта «җирлекләр арасында» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

г) 14 пунктта «медицина учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә, «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү гарантияләре» сүзләрен «гражданнарга медицина ярдәме түләүсез күрсәтү гарантияләре» сүзләренә алмаштырырга;

д) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыюны, алып китүне оештыру, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү»

е) 10 пунктта «авылара» арасында сүзне төшереп калдырырга;

ж) 21 пунктта «авылара» арасында сүзне төшереп калдырырга;

з) 23 пунктта «районда халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу» сүзтезмәләр өстәргә;

и) 28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28) җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны җиһазландыруны оештыру, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иректе үтеп керүен тәэмин итүне дә кертеп;»

к) 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32) Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, халыкка аларны куллану чикләүләре турында мәгълүмат бирү;»

л) 35, 38 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

м) 39 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аларга карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган җирлекләрнең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплексы үстерү программаларын, җирлекләрнең транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программаларын, җирлекләрнең социаль инфраструктурасын комплексы үстерү программаларын эшләү һәм раслау»;

н) түбәндәге эчтәлекле 41-51 пунктларын өстәргә:

«41) муниципаль районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру»;

42) адреслар бирү, адресларны үзгәртү, юкка чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый атамаларны үзгәртү, юкка чыгару, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыру.».

43) район җирлекләрендә яшәүчеләрне һәм аз керемле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗларны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен тәэмин итү;»

44) район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкярләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру, мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкярләрне) саклау;

45) җирлек территориясендә авария-коткару хезмәтләре һәм (яки) авария-коткару формированиеләрен төзү, карап тоту һәм аларның эшчәнлеген оештыру;

46) җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру;

47) Район чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан торгызуа.

48) җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү, җирлекләрне шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау., җирләрне резервлау һәм җирләрне тартып алу, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда гамәлгә ашыру, биналарны, корылмаларны карау һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында

рекомендацияләр бирү.

49) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

50) район территориясендә авария-коткару хезмәтләрен һәм (яки) авария-коткару формированиеләрен төзү, карап тоту һәм аларның эшчәнлеген оештыру.

51) «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау;

2) 8 статьяда:

а) 5 өлештә «югары һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре» сүзләрен «югары белем бирү мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 8 пунктны өстәргә:

«8) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру.»;

3) 6 статьяның 3 пункты 3 пунктчасына «территорияләрне планлаштыру проектлары һәм территорияләрне ызанлау проектлары» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очраклардан « сүзләрен өстәргә.

4) 27 статьяның 7 пунктында:

а) 1 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

б) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхси яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләре ширкәтеннән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һөнәр берлекләреннән тыш) катнашырга, әгәр федераль законнарда яисә федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә башкасы каралмаган булса, аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса».

5) 42 статьяда:

а) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«Муниципаль район башлыгына муниципаль сайлауларда сайланган затларга карата счетлар (кертемнәр), Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча средстволарын һәм кыйммәтләрне саклау, күрсәтелгән затлар муниципаль район башлыгы сайлауларында кандидатлар буларак теркәлгән чорда чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) файдалану фактын билгеләү;»

б) түбәндәге эчтәлекле 5-9 өлешләр өстәргә:

« 5. Муниципаль сайлауларда сайланган муниципаль район башлыгы, аның вәкаләтләре муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә вакытыннан алда туктатылган булса, күрсәтелгән карарга суд тәртибендә шикаять бирсә, муниципаль район башлыгын вакытыннан алда сайлаулар суд карары законлы көченә кергәнче билгеләнергә мөмкин түгел.

6. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы составыннан сайланган муниципаль район башлыгы, аның вәкаләтләре муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә вакытыннан алда туктатылган булса, күрсәтелгән карарга суд тәртибендә шикаять бирсә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы үз составыннан суд карары законлы көченә кергәнче муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында Карар кабул итәргә хокуклы түгелү.

7. Муниципаль берәмлек башлыгын үз составыннан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы итеп сайлауны күздә тоткан Россия Федерациясе субъекты законы кабул ителгән очракта, муниципаль берәмлек башлыгын сайлаулар билгеләнми һәм үткәрелми, әгәр Россия Федерациясе субъектының күрсәтелгән законы датага кадәр үз көченә керген булса, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре

турында»2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек башлыгын сайлауларны билгеләү турында Карар кабул итәргә хокуклы булыр иде.

8. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан аны отставкага җибәрү турында Карар кабул ителгән муниципаль район башлыгы әлеге карарга карата шикаять белдерү турындагы гариза белән мондый карар рәсми басылып чыккан көннән 1 көн эчендә судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Суд гаризаны карарга һәм гариза биргән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча карар кабул итәргә тиеш .

9. Әлеге статьяның 8 өлеше нигезләмәләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 36 һәм 74.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 4 октябрендәге 290-ФЗ номерлы федераль закон үз көченә кергән көннән соң кабул ителгән муниципаль берәмлек башлыкларын отставкага җибәрү турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарына шикаять белдерүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Әлеге Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр кабул ителгән отставкага муниципаль район башлыгын чыгару турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарына шикаять бирү турындагы гаризаларны карау һәм хәл итү сроклары, әлеге статьяның 3 өлешендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 256 һәм 257 статьялары нигезләмәләре нигезендә билгеләнә.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законның 36 һәм 74.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 4 октябрендәге 290-ФЗ номерлы федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр кабул ителгән муниципаль район башлыгын отставкага җибәрү турында муниципаль районның вәкиллекле органы карарына шикаять бирү турында гариза судка «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законның 36 һәм 74.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 4 октябрендәге 290-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көннән соң судка тапшырыла, һәм шул ук вакытта закон белән билгеләнгән чор тәмамланганчы 10 көннән дә кимрәк вакыт калып бара, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының күрсәтелгән карары нигезендә муниципаль район башлыгының вакытыннан алда сайлау билгеләнергә тиеш, суд гаризаны карый һәм тиешле вакытыннан алда сайлаулар билгеләнгән көнгә кадәр карар кабул итә.

б) 45 статьяда:

а) 2 өлеш:

- түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыра.»;

- 6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашыра;»

б) 9 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

« - көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны, чыгаруны оештыру, көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртү;»

- түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«-муниципаль районның авылара территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру»;

- район чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләренең урманнардан файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызуны оештыру.

җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, төзелешкә рөхсәтләр

бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү, җирлекләрне шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын раслау., җирләрне резервлау һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда җирләрне тартып алу, гамәлгә ашыру, биналарны, корылмаларны карау һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирү.

- муниципаль урман контролен тормышка ашыру;

- Россия Федерациясенең су законнары белән билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыра, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгели, халыкка аларны куллану чикләүләре турында хәбәр итә;

- «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.»

в) 4 өлеш:

- 3 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«-район чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыра, район чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын муниципаль контрольдә тота һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итә, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыруны һәм эшләвен тәэмин итә, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;»

4 абзацта «җирлекләр арасында» сүзтезмәсен төшереп калдырырга.

- г) 5 өлеш:

- 12 абзац үз көчен югалткан дип танырга;

- 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - район чикләрендә халыкны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә электр, җылылык, газ белән тәэмин итүне оештыру;»

- 5 һәм 6 абзацларда «җирлекара " сүзтезмәләрен төшереп калдырырга.

- 7 абзацта «районда халык сәнгать һөнәрчелеген саклауда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу»дигән сүзләр өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

- объектларга адреслар бирә, адресларны үзгәртә, аннулировать итә, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), муниципаль районның авылара территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирә, мондый исемнәрне үзгәртә, гамәлдән чыгара, мәгълүматны дәүләт адрес реестрында урнаштыра.».

район җирлекләрендә яшәүче һәм аз керемле торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итә, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыра, торак төзелеше өчен шартлар тудыра, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыра, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;»

- район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне) саклауны, куллануны һәм популярлаштыруны, район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкярләрне) саклауны тәэмин итә;

- җирлек территориясендә авария - коткару хезмәтләре һәм (яки) авария-коткару формированиеләре эшчәнлеген булдыра, тәэмин итә һәм тәэмин итә;

- халык күпләп ял итә һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыра;»

д) 6 өлешнең 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«-муниципаль район территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыра (халкы башкарма хакимиятнең аерым территорияләр халкын медик-санитар тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы карамагындагы медицина оешмаларында медицина ярдәме белән тәэмин ителә торган территорияләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлегенә кертелгән җирлекләр территорияләреннән тыш) гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы нигезендә аерым территорияләр халкына медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыра;»

е) 7 өлештә 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«-җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыра һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыра, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итә».

7) 47 статьяның 2 пункты 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы - тиешле муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы, ә икенче яртысы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.».

7) 74 статьяның 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль норматив хокукый, хокукый актларны рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет-ресурсында хокукый акт текстын бастырып чыгару юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.»

75 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

«75 статья. Районның муниципаль мөлкәте

Район милкендә булырга мөмкин:

1) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук район җирле үзидарә органнарының федераль законда каралган тәртиптә үзләренә тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) район Советының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр хезмәткәрләре, учреждение хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен;

4) хәл итү хокукы федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен.

2. Район милкендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка милек була ала..»

10) 80 статьяның 7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Чираттагы финанс елына һәм план чорына район бюджеты проектын төзү нигезләнә:

2. Бюджет проектларын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

РФ Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесе юлламасы нигезләмәләре;

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы;

бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

районның социаль-икътисадый үсеше фаразлары;

бюджет фаразлары;

муниципаль программалар.»

11) 81 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

81 Статья. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу.

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт снстемасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен эшләр, хезмәтләр сатып алу җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны башкару һәм тикшереп тору район Советы тарафыннан билгеләнә.

2. Тукай муниципаль районы башлыгы урынбасары Л.Х. Әхмәтовага әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Контроль.әлеге карарны үтәү өчен законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
Совет рәисе — В.Г. Хаҗиев